**Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы Хөкүмәте арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турында**

# КИЛЕШҮ

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов йөзендә Татарстан Республикасы бер яктан, һәм Тыва Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Тыва Республикасы Башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Шолбан Валерьевич Кара-оол йөзендә Тыва Республикасы Хөкүмәте икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып,

Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм Тыва Республикасы законнары нигезендә,

үзләренең хокукларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра килеп,

тотрыклы һәм озак вакытка исәпләнгән ике яклы элемтәләрне үстерүдә үзара кызыксыну күрсәтеп һәм моның өчен тиешле оештыру, икътисадый, хокукый һәм кирәкле башка шартлар тудырырга теләп,

социаль һәм иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендәге хезмәттәшлекнең яшәп килүче традицияләренә нигезләнеп,

Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасының фәнни-техник, производство һәм мәдәни потенциалын игътибарга алып,

ике яклы хезмәттәшлекне үстерү халыкның мәнфәгатьләренә җавап бирүен, Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасының икътисадый үсешенә этәргеч бирүен танып,

Якларның дәүләт хакимияте башкарма органнарының нәтиҗәле хезмәттәшлеген, социаль-икътисадый эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә тәҗрибә алмашуга һәм даими мәгълүмати хезмәттәшлеген тәэмин итүгә омтылып,

үз мөнәсәбәтләрен ышаныч, тигез хокуклылык, партнерлык, ихтирам, үзара файда, Килешү нигезләмәләрен һәм ирешелгән сүз куешуларны үтәү өчен һәр ике якның да җаваплылыгы нигезендә үстерә килеп, әлеге Килешүне түбәндәгеләр турында төзеделәр.

## 1 статья

Яклар әлеге Килешүнең нигезләмәләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат алмаша, Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы законнарында әлеге Килешү кысаларында хезмәттәшлеккә бәйле мәсьәләләр буенча планлаштырыла торган үзгәрешләр турында бер-берсенә хәбәр итә.

## 2 статья

Яклар Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасының сәнәгать, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә, авыл хуҗалыгы, сәүдә һәм хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау, мәгариф, архитектура һәм шәһәр төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык, транспорт һәм транспорт инфраструктурасы, фән,

мәдәният, туристлык һәм спорт, яшьләр сәясәте, балалар хокукларын һәм аларның законлы мәнфәгатьләрен яклау, әйләнә-тирә мохитне саклау кебек өлкәләрдә, шулай ук үзара кызыксыну тудыручы башка өлкәләрдә хезмәттәшлек итүе өчен уңай шартлар тудыруга ярдәм итә.

**3 статья**

Яклар үз территорияләрендә икътисадый сәясәтне уздыруда үзара ярдәм итешә һәм килешенгән гамәлләр кыла, товар әйләнешенең, үзара түләүләр һәм исәп-хисапларның сыгылмалы механизмнарын булдыруны, инвестиция проектларын һәм халыкны социаль яклауның дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә. Яклар үзара хезмәттәшлекнең ел саен төгәллекләр кертелергә мөмкин булган өстенлекле юнәлешләрен билгели.

**4 статья**

Яклар Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы территорияләрендә эшчәнлек алып баручы хуҗалык субъектлары (алга таба – Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы хуҗалык субъектлары) арасында сәүдә-икътисадый элемтәләрне урнаштыру һәм киңәйтү өчен шартлар тудыра, производство-техник билгеләнештәге продукциянең әһәмиятле төрләрен, авыл хуҗалыгы чималын, азык-төлек, халык кулланышы товарларын бер-берсенә китерү һәм үзара хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашыруга ярдәм итә.

**5 статья**

Яклар Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасының социаль-икътисадый үсеш проблемаларын хәл итү белән бәйле уртак проектларны һәм дәүләт программаларын эшләү кысаларында тәҗрибә, мәгълүмат алмашу һәм консультация ярдәме күрсәтүне башкара.

**6 статья**

Яклар Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасының социаль-икътисадый үсеш проблемаларын хәл итү белән бәйле проектларны һәм дәүләт программаларын эшләүгә фәнни-тикшеренү һәм башка оешмаларны җәлеп итүгә ярдәм итә.

**7 статья**

Яклар уртак инвестиция һәм инновация эшчәнлеген, шул исәптән чит ил капиталын җәлеп итеп тә, башкаруга ярдәм итә, шулай ук дәүләт-хосусый партнерлыгы өлкәсендә тәҗрибә алмаша.

**8 статья**

Яклар элемтә, мәгълүмат һәм телерадиотапшырулар өлкәсендә хезмәттәшлек итүне һәм тәҗрибә алмашуны башкара. Якларның дәүләт хакимияте органнары һәм Яклар территориясендә урнашкан җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тәэмин итү өчен мәгълүмати-коммуникация технологияләрен гамәлгә кертү, халыкка мәгълүмати дәүләт хезмәте күрсәтүләр мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирүне башкара.

**9 статья**

Яклар Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы оешмаларының җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре, архитектура һәм шәһәр төзелеше, Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы территориясендә сәнәгать билгеләнешендәге һәм гражданнарга хезмәт күрсәтүче объектларны урнаштыру һәм төзү, территорияне, юл хуҗалыгын төзекләндерү, транспорт юлларын үстерү өлкәсендә хезмәттәшлеген оештыра, мәгълүмат һәм эш тәҗрибәсе уртаклаша.

**10 статья**

Яклар Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арасында эшлекле элемтәләрне урнаштыру һәм киңәйтүгә ярдәм итә, үз компетенцияләре чикләрендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм күрсәтү проектларын эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга юнәлтелгән эшчәнлекне бергәләп алып бара, шулай ук Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү инфраструктурасы оешмалары арасында хезмәттәшлек, мәгълүмат һәм тәҗрибә алмашу мәсьәләләрен карап тикшерә.

**11 статья**

Яклар халык сәламәтлеген саклау, Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасында яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтү өлкәсендә хезмәттәшлек итә, Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы дәвалау-профилактика учреждениеләре арасында элемтәләрне үстерүгә булышлык итә, медицина хезмәткәрләре делегацияләре белән алмаша.

**12 статья**

Яклар Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы оешмалары арасында турыдан-туры элемтәләр нигезендә мәдәният, спорт, туристлык өлкәсендә һәм социаль-мәдәни тормышның башка өлкәләрендә элемтәләрне үстерүгә һәм ныгытуга ярдәм итә, мәдәни хезмәттәшлек программаларын

гамәлгә ашыруда, сәнгать һәм музей күргәзмәләрен, һөнәри иҗат коллективлары, спорт командалары чыгышларын оештыруда ярдәм күрсәтә.

Яклар төбәк иҗтимагый берләшмәләре, шул исәптән якташлык җәмгыятьләре белән, Россия милләтенең бердәмлеген ныгыту һәм Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы халыкларының этномәдәни үсеше, яшьләргә патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү, аны спорт белән шөгыльләнүгә тарту һәм сәламәт яшәү рәвеше белән мавыктыру, шулай ук төбәкара характердагы чараларны оештыру һәм уздыру мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә.

## 13 статья

Яклар Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы субъектларының эшкуарлык яисә хуҗалык эшчәнлеге, алар арасында элемтәләрне киңәйтү һәм базар мөнәсәбәтләрен, шул исәптән Якларның электрон сәүдә мәйданчыкларыннан файдаланып та, үстерү өчен уңай шартлар булдыра.

## 14 статья

Яклар халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерә, әлеге өлкәләрдә комплекслы дәүләт программаларын эшләү буенча, шул исәптән балалы, өлкән буын вәкилләре, инвалидлар, инвалид балалар булган гаиләләргә ярдәм күрсәтү, балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуын кисәтү, инвалидлар өчен яшәү тирәлеген җайлаштыру, яңа социаль технологияләр эшләү буенча хезмәттәшлек итә һәм тәҗрибә алмаша, шулай ук халыкны социаль яклау хезмәтләре, тернәкләндерү учреждениеләре эшчәнлеге турында мәгълүмат алмаша.

## 15 статья

Яклар әйләнә-тирә мохитнең торышы турында, шулай ук табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә нормалар язу буенча тәҗрибә алмашуны башкара.

Яклар әйләнә-тирә мохитне саклау, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шулай ук янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләре буенча тәҗрибә алмашуны башкара, аварияләр, һәлакәтләр һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерүдә үзара ярдәм итешә.

## 16 статья

Яклар үз вәкаләтләре чикләрендә кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен тәэмин итү һәм яклау, коррупциягә, террорчылыкка һәм

экстремистлыкка каршы тору, җинаятьчелеккә каршы көрәшү, милекне һәм җәмәгать тәртибен саклау чараларын үтәү буенча эш тәҗрибәсе алмаша.

**17 статья**

Яклар хезмәттәшлек юнәлешләре буенча уртак күргәзмәләр, конференцияләр, семинарлар, киңәшмәләр, «түгәрәк өстәлләр» һәм башка чаралар уздыруны оештыра.

Күргәзмә-ярминкә эшчәнлеген координацияләү максатында Яклар Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы территорияләрендә төбәкара һәм халыкара күргәзмәләр һәм ярминкәләр оештыру һәм уздыру планнары белән уртаклаша һәм аларда төбәктәге товар җитештерүчеләрнең катнашуына ярдәм итә.

**18 статья**

Әлеге Килешү Яклар тарафыннан хезмәттәшлекнең конкрет өлкәләрендә шартнамәләр, килешүләр, планнар һәм беркетмәләр төзү өчен нигез булып тора.

Әлеге Килешү аңа кул куйган Якларга финанс һәм мөлкәт йөкләмәләре салмый.

**19 статья**

Әлеге Килешүне төзү һәм гамәлгә ашыру Якларның күпьяклы төбәкара элемтәләрен үстерү эшчәнлегенең бер өлеше булып тора һәм аларның теләсә нинди өченче Як алдындагы йөкләмәләрен үтәүләре өчен киртә була алмый.

**20 статья**

Яклар икенче Якка икътисадый яисә башка төрле зарар китерергә мөмкин булган гамәлләрдән тыелып кала, аларны кабул итү икенче Якның хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылуы мөмкин булган карарларны бер-берсе белән килештерә яисә алар турында алдан хәбәр бирә.

**21 статья**

Әлеге Килешү нигезләмәләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итү, шулай ук Яклар төзегән өстәмә килешүләрне (беркетмәләрне, планнарны) гамәлгә ашыру барышына күзәтчелеккә ярдәм итү өчен Яклар делегацияләре яисә аерым вәкилләре катнашында ике яклы очрашулар, сөйләшүләр, утырышлар, киңәшмәләр һәм башка чаралар уздырылырга мөмкин.

**22 статья**

Әлеге Килешү нигезләмәләрен шәрехләүдә һәм кулланганда, яисә үтәгәндә аның гамәле кысаларын аңлауда килеп чыгуы мөмкин булган фикер төрлелеген Яклар консультацияләр һәм сөйләшүләр юлы белән хәл итәргә тиеш.

**23 статья**

Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасы һәм Тыва Республикасы бюджет турындагы законнары нигезендә Яклар бюджетлары акчалары хисабыннан башкарылырга тиешле әлеге Килешүне гамәлгә ашыру чаралары Яклар тарафыннан тиешле финанс елына һәм планлаштырылган чорга алар бюджетында карала торган бюджет ассигнованиеләре хисабыннан билгеләнгән тәртиптә финанслана.

**24 статья**

Килешү Яклар тарафыннан аларның уртак ризалыгы белән үзгәртелә ала. Барлык үзгәрешләр аерым өстәмә килешүләр белән рәсмиләштерелә.

Килешү аңа кул куелган вакыттан үз көченә керә һәм 5 (биш) ел буе гамәлдә була. Әгәр дә Якларның берсе дә әлеге Килешүнең гамәле чыгарга өч ай кала Килешүнең гамәлен туктатырга нияте барлыгы турында язмача хәбәр итмәсә, ул үзеннән-үзе шундый ук вакытка озайтыла.

Кызыл шәһәрендә 2016 елның «1» июленда һәр Як өчен берәр, һәрберсе рус һәм татар телләрендә ике нөсхәдә башкарылды.

Нинди дә булса төгәлсезлекләр яисә терминнарның мәгънә ягыннан эчтәлеге туры килмәү очраклары килеп чыкса, рус телендәге текст өстенлекле була.

| | |
|---|---|
| **Татарстан Республикасы өчен** | **Тыва Республикасы Хөкүмәте өчен** |
| **Татарстан Республикасы Президенты** | **Тыва Республикасы Башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** |
| **Р.Н. Миңнеханов** | **Ш.В. Кара-оол** |

02.07.2016
№26